КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 30 ноябрь г.Казань № 1150

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 – 2023 елларда «Мәгариф» милли проектының «Заманча мәктәп» федераль проекты кысаларында Татарстан Республикасының авыл җирлекләрендә һәм кече шәһәрләрендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында табигый-фәнни һәм технологик юнәлештәге мәгариф үзәкләрен булдыру һәм эшләтү чараларын тормышка ашыру турында» 2020 ел, 25 декабрь, 1191 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 – 2023 елларда «Мәгариф» милли проектының «Заманча мәктәп» федераль проекты кысаларында Татарстан Республикасының авыл җирлекләрендә һәм кече шәһәрләрендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында табигый-фәнни һәм технологик юнәлештәге мәгариф үзәкләрен булдыру һәм эшләтү чараларын тормышка ашыру турында» 2020 ел, 25 декабрь, 1191 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 15 март, 134 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта «2021 – 2023 елларда» сүзләрен өстәргә;

Татарстан Республикасының авыл җирлегендә һәм кече шәһәрләрендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында «Үсеш ноктасы» табигый-фәнни һәм технологик юнәлештәге мәгариф үзәкләрен булдыру һәм эшләтү чаралары комплексын («юл картасын») яңа редакциядә (карарга теркәлә) расларга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин